**«РАСЛЫЙМ»**
**Татарстан Республикасы**
**мәгариф һәм фән министры**
**_____________ И.Г.Һадиуллин**
**«19» ноябрь 2025 нче ел**

# Туган телдә белем бирү оешмалары укучылары өчен 2026 нчы елда туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру материалларының үзенчәлекләре (спецификация)

# Спецификация
## контрольных измерительных материалов для проведения государственной итоговой аттестации по образовательным программам основного общего образования 2026 года по родному (татарскому) языку для обучающихся школ с родным языком обучения

разработан федеральным государственным автономным образовательным учреждением высшего образования
«КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ»

подготовлен государственным бюджетным учреждением
«РЕСПУБЛИКАНСКИЙ ЦЕНТР МОНИТОРИНГА КАЧЕСТВА ОБРАЗОВАНИЯ»

утвержден МИНИСТЕРСТВОМ ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## 1. Дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру материалларының максаты

Төп дәүләт имтиханы (ТДИ) дәүләт йомгаклау аттестациясе формасын тәшкил итә. Укучыларның төп гомуми белем бирү программаларын үзләштерү нәтиҗәләренең Федераль дәүләт белем бирү стандарты таләпләренә туры килүен билгеләү максатыннан гамәлгә ашырыла. Әлеге максаттан стандартлаштырылган биремнәрдән гыйбарәт тикшерү материаллары тәкъдим ителә.

## 2. Дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру материаллары эчтәлеген билгели торган документ

Дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру материаллары түбәндәге документка нигезләнеп эшләнә:

Примерная рабочая программа учебного предмета «Родной (татарский) язык» для 5–9 классов основного общего образования для образовательных организаций с обучением на родном (татарском) языке / Разработчики: Шакурова М.М., Гиниятуллина Л.М. //

https://fgosreestr.ru/uploads/files/51cb63e57e2ee54667b15e3618a30341.pdf

## 3. Дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру материалларының төзелешен һәм эчтәлеген билгеләү алымнары

Норматив документлар, илебез мәгарифе традицияләре һәм дәүләт йомгаклау аттестациясе максатлары, белем бирү сыйфатын бәяләү өлкәсендәге заманча тенденцияләр имтихан моделе структурасын булдыру, эчтәлекне сайлауның концептуаль алымнарын билгелиләр.

Туган (татар) тел буенча төп дәүләт имтиханы моделен төзүдә төп концептуаль алымнар түбәндәгеләр:

- әлеге модель кысаларында түбәндәге компетенция төрләрен тикшерүне үз эченә алган компетентлы якын килү алымы:

• лингвистик компетенцияне, ягъни тел материалы белән эшләгәндә, лингвистик белемнәрне куллана алуны тикшерә;

• тел компетенциясен, ягъни укучыларның тел нормаларын (лексик, грамматик, стилистик, орфографик, пунктуацион) үтәү белән бәйле осталыклары һәм күнекмәләрен тикшерә;

• коммуникатив компетенцияне, ягъни укучыларның сөйләм эшчәнлегенең төрле төрләренә ия булуын, чит сөйләмне кабул итү алуын тикшерә;

• мәдәни компетенцияне, ягъни телнең милли мәдәниятне белдерү формасы булуын, тел белән халык тарихы бәйләнешен, татар теленең милли-мәдәни үзенчәлеген аңлауны һәм үз фикерен белдерә алуын тикшерә.

- имтихан бирүченең тел һәм сөйләм күнекмәләрен бәяләү бердәмлегендә чагыла торган интегратив якын килү алымы;

- коммуникатив якын килү алымы. Аның нигезен мәктәпне тәмамлаучының коммуникатив практикасының тотрыклылыгын һәм уңышлы булуын тәэмин иткән коммуникатив белемнәрнең формалашуын тикшерә торган биремнәр системасы тәшкил итә;

- когнитив алым. Биремнәрнең чагыштыру, анализ, синтез, абстракция, гомумиләштерү, классификация, конкретлаштыру, билгеле бер закончалыкларны һәм кагыйдәләрне билгеләү кебек универсаль гамәлләрне тормышка ашыру сәләтен тикшерүгә юнәлгәнлеге белән бәйле;

- шәхси якын килү алымы. Имтихан моделенең чыгарылыш укучыларының мөмкинлекләренә, ихтыяҗларына юнәлгәнлеген, имихан ташыручыларның әзерлек дәрәҗәләренә һәм интеллектуаль мөмкинлекләренә җайлашуын күз алдында тота.

Туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру материаллары сайлап алу мөмкинлеген истә тотып төзелгән: укучы ике сочинениенең берсен сайлап алып яза.

Күрсәтелгән алымнар үзара бәйле һәм бер-берсен тулыландыралар.

Аерым биремнәрне һәм тестны гомумән бәяләү системасы педагогик үлчәүләр теориясе һәм практикасы таләпләрен һәм туган (татар) телне укыту традицияләрен истә тотып эшләнгән.

## 4. Дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру материалларының төзелеше һәм эчтәлегенә аңлатма

Дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру материаллары формасы һәм катлаулылыгы ягыннан төрле булган 9 биремне эченә алган 3 бүлектән тора.

1 бүлек - кыска изложение (1 нче бирем).

2 бүлек - кыска җавап бирүне таләп иткән 7 бирем (2-8 нче биремнәр).

Имтихан эшендә кыска җавап бирүне таләп иткән түбәндәге төрдәге биремнәр тәкъдим ителә:

- укучы үзе формалаштырган кыска җавапны яза торган ачык типтагы биремнәр;
- тәкъдим ителгән җавап вариантларыннан дөрес номерларны сайлап алып яза торган биремнәр.

3 бүлек - укылган текст нигезендә үз фикереңне белдерә алуны тикшерүгә юнәлдерелгән, киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән, ачык типтагы бирем ( 9 нчы альтернатив бирем - сочинение).

Биремнәрнең чагылышы 1 нче таблицада бирелә.

**Биремнәрнең бүлекләрдә бирелеше**

*1 нче таблица*

| Тестның бүлекләре | Биремнәрнең саны | Иң югары башлангыч балл | Бирем төрләре |
|---|---|---|---|
| 1 нче бүлек | 1 (1 нче бирем) | 7 | Киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән |
| 2 нче бүлек | 7 (2-8 нче биремнәр) | 7 | Кыска җавап бирүне таләп иткән биремнәр |
| 3 нче бүлек | 1 (9 нчы бирем) | 9 | Киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән |
| 1 нче һәм 3 нче бүлекләр | | Грамоталылык һәм сөйләмнең төгәллеге өчен **10** | |
| Барлыгы: | 9 | 33 | |

**5. Биремнәренең эчтәлеге һәм тикшерелә торган эш төрләре буенча бүленеше**

**Биремнәрнең “Туган (татар теле)” предметының төп эчтәлеге буенча бүленеше**

*2 нче таблица*

| Бүлекләрнең исеме | Биремнәр саны | Иң югары башлангыч балл | Иң югары башлангыч баллдан чыгып, әлеге бирем өчен куелган иң югары балл (процентларда) |
|---|---|---|---|
| Сөйләм. Тыңлау. Телдән сөйләмне дөрес аңлау. Изложение. Тыңлаган текстны язмача кыска формада бирү (кыска изложение) | 1 | 7 | 21 |
| Синтаксис | 1 | 1 | 3 |
| Фонетика | 1 | 1 | 3 |
| Пунктуация | 1 | 1 | 3 |
| Морфология | 1 | 1 | 3 |
| Сөйләм. Уку. Язмача сөйләмне дөрес аңлау | 1 | 1 | 3 |
| Лексикология һәм фразеология | 1 | 1 | 3 |

| **Бүлекләрнең исеме** | **Биремнәр саны** | **Иң югары башлангыч балл** | **Иң югары башлангыч баллдан чыгып, әлеге бирем өчен куелган иң югары балл (процентларда)** |
|---|---|---|---|
| Сөйләм. | 2 | 10 | 30 |
| Сөйләм эчтәлегенең төгәллеге һәм грамоталы булуы. | 1 нче һәм 3 нче бүлекләрдә (гомуми) | 10 | 31 |
| Барлыгы | 9 | 33 | 100 |

Дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру материаллары төрләре ягыннан аерыла (3 нче таблицаны кара). Укучылар текстта бирелгән тел күренешләре белән эш итә. Алар әзер тексттан тиешле материалны табып эшли, монологик сөйләм төзи.

**Тел материалы белән эшләү төрләре ягыннан биремнәрнең бүленеше**

*3 нче таблица*

| **Эш төрләре** | **Биремнәр саны** | **Иң югары башлангыч балл** | **Иң югары башлангыч баллдан чыгып, имтихандагы тел материалы белән эш төрләре өчен куелган иң югары балл (процентларда)** |
|---|---|---|---|
| Изложение язу | 1 | 7 | 21 |
| Текстта бирелгән тел материалы белән эшләү | 7 | 7 | 21 |
| Сочинение язу | 1 | 9 | 27 |
| Грамоталылык һәм фактик төгәллек | | 10 (изложение һәм сочинение язу нигезендә) | 31 |
| Барлыгы: | 9 | 33 | 100 |

**6. Биремнәренең катлаулылык дәрәҗәсе ягыннан бүленеше**

Барлык биремнәр нигез дәрәҗәгә карый.

**7. Эшне башкару вакыты**

Дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру өчен, 3 сәгать 55 минут (235 минут) вакыт бирелә.

**8. Өстәмә материаллар һәм җиһазлар**

Дәүләт йомгаклау аттестациясен уздырганда, орфографик сүзлекләрдән файдаланырга рөхсәт ителә.

**9. Аерым биремнәрне һәм барлык эшне бәяләү системасы**

**1 нче бүлектәге** 1 нче бирем (кыска изложение) махсус төзелгән критерийлар буенча бәяләнә. Кыска изложение өчен иң югары балл **– 7.**

**2 нче бүлектәге** 2-8 нче биремнәрдә һәр дөрес җавап өчен укучыга 1 балл куела. Җаваплар биремнәрне үтәү күрсәтмәсендәгечә язылган булса һәм дөрес җавап үрнәге белән тулысынча туры килсә, бирем дөрес үтәлгән дип санала. Биремнәрнең җавапларын язганда, символлар тәртибе әһәмиятле түгел. Ялгыш җавап бирелсә яки җавап булмаса 0 балл куела. Бу бүлектә дөрес җаваплар өчен укучы иң югары **7 балл** җыя ала.

**3 нче бүлектәге** бирем махсус төзелгән критерийлар буенча бәяләнә. Альтернатив бирем өчен **иң югары балл** – **9.**

Изложение һәм сочинениене тикшерү нәтиҗәсе буенча укучының **грамоталылыгы** һәм язма сөйләмдәге төгәллеге өчен **10 балл** куела.

Имтиханның барлык биремнәрен үтәгән өчен, укучы җыярга мөмкин булган **иң югары балл – 33.**

Беренче һәм икенче тикшерү нәтиҗәләре буенча экспертлар бер-берсенә бәйсез рәвештә һәр киңәйтелгән җавап таләп иткән бирем өчен беренчел баллар куялар.

Ике эксперт тарафыннан куелган беренчел балларда шактый аерма булган очракта өченче тикшерү билгеләнә.

Өченче эксперт, предмет комиссиясе рәисе белән килешенеп, имтихан эшен тикшермәгән экспертлар арасыннан билгеләнә.

Өченче экспертка имтихан эшен тикшергән экспертлар тарафыннан куелган беренчел баллар турында мәгълүмат бирелә.

1 нче һәм 9 нчы биремне үтәгән өчен, ике эксперт куйган баллар суммасы (биремнәрнең үтәлешен бәяли торган барлык бәяләү позицияләре (критерийлары): ИК1–ИК3, С1К1-С1К4, С2К1–С2К4, ГК1–ГК4, ФК1 буенча куелган баллар кушыла) арасындагы аерма 8 яки шуннан күбрәк булса, өченче эксперт 1 нче һәм 9 нчы биремнең үтәлешен барлык критерийлар буенча бәяли.

Экспертларның берсе имтихан эшендә җавап булмавын күрсәткән, ә башка эксперт, шул биремне үтәгән өчен, 0 балл куйган очракта биремнең үтәлешен бәяләүдә әһәмиятле аерма юк дип санала.

**10. Дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру шартлары (белгечләргә таләпләр)**

Туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясе уздырыла торган аудиториягә филолог белгечләр кертелми. Имтиханны туган (татар) тел һәм әдәбиятны укытмый торган педагог уздырырга тиеш.

Киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән биремнәрнең дөреслеген дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру буенча махсус әзерлек узган туган (татар) тел белгечләре тикшерә.

**Дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру шартлары (белгечләргә карата куела торган таләпләр)**

**Имтиханның тәкъдим ителә торган тәртибе** түбәндәгечә:

1. Имтихан материаллары салынган пакетны алгач, укучылар бирем эшлисе бланкларга имзаларын куя, аннары аларны өстәлгә тәртибе буенча җыеп куя. Эш барышында алар тиешле формада тутырыла.
2. Башта укучыларга, изложение язу өчен, текст укыла. Бу вакытта алар караламага үзләренә кирәк дип санаган сүзләрне язып бара ала. Икенче тапкыр тыңлагач, укучылар аның эчтәлеген кыскача яза. Изложение тексты аудиоязмада тыңлана.

Кыска изложениене үткәрү үрнәге:

*1 нче таблица*

| № | Оештыру эше | Укучылар эше | Бирелә торган вакыт |
|---|---|---|---|
| 1 | Аудиоязманы беренче кат тыңлау | Укучылар текстны тыңлыйлар, караламага кайбер сүзләрне язып баралар | 3 – 4 минут |
| 2 | Уйлану өчен бераз вакыт бирелә | Укучылар каралама белән эшлиләр | 5-6 минут |
| 3 | Аудиоязманы икенче кат тыңлау | Укучылар текстны кабат тыңлыйлар | 3 – 4 минут |
| 4 | Аудиоязманы туктату, изложение яза башларга һәм орфографик сүзлекләрдән файдаланырга рөхсәт бирелә | | |
| 5 | | Укучылар кыска изложение язалар. | |

3. Аннан соң укучыларга, имтиханның ның икенче бүлеген үтәү өчен, текст таратыла. Алар укылган текстның эчтәлеген чагылдырган һәм лингвистик анализ ясауга бәйле биремнәрне үтиләр.

**Дәүләт йомгаклау аттестациясенең барлык бүлекләрендәге биремнәрне үтәгәндә, укучыларга орфографик сүзлектән файдаланырга рөхсәт ителә.**

**11. Дәүләт йомгаклау аттестациясенә әзерләнү өчен кайбер киңәшләр**

Имтиханга әзерләнгәндә, укучыларга татар теленнән урта гомуми белем бирү мәктәпләренә Россия Федерациясе мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән гамәлдәге дәреслекләрдән һәм уку әсбапларыннан, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы рөхсәте белән чыгарылган ярдәмлекләрдән, күрсәтмә материаллардан файдаланырга киңәш ителә.

*Кушымта*

## 2026 нчы елда Дәүләт йомгаклау аттестациясе материалларының гомумиләштерелгән планы

*Барлык биремнәр дә нигез дәрәҗәгә карый.*

| № | Тикшерелә торган эчтәлек элементлары | Тикшерелә торган эчтәлек кодлары | Тикшерелә торган күнекмәләрнең кодлары | Бирем өчен иң югары балл | Биремне үтәү вакыты (мин) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Тыңланган текст буенча кыска изложение язу. | 11 | 1.2 | 7[1] | 90 |
| 2. | Синтаксис | 5.3<br>5.10 | 4.6 | 1 | 13 |
| 3. | Фонетика | 1.2 | 4.1 | 1 | 12 |
| 4. | Пунктуация | 5.1 | 7.1 | 1 | 12 |
| 5. | Морфология | 4.1<br>4.2 | 4.4 | 1 | 12 |
| 6. | Текстка анализ | 8.3<br>8.5<br>5.11 | 4.7 | 1 | 12 |
| 7. | Лексикология | 2.4 | 2.1 | 1 | 12 |
| 8. | Сөйләм | 10.2 | 4.2 | 1 | 12 |
| 9. | Сочинение язу | 8.6 | 1.3 | 1 | 60 |

[1] 1 һәм 9 нчы биремнәрен тикшергәндә грамоталык һәм сөйләмнең төгәллеге изложение белән сочинение тикшерүгә нигезләнеп башкарыла һәм 10 баллга тигез.